4 МИЛЛИОН

Узган ел республикага әнә шулкадәр турист килгән. Быел тагын да күбрәккә өметләнәләр

> 2

РАЗИФ ХАФИЗОВ:

«Очраклы гына газета кулыма килеп керде дә, әллә нәрсә булды: йөрәгем кысылып куйды»

> 3

ТАРИХ = КОМЕДИЯ?

Татар киносына әле ниләр күрәсе?

> 4

ИСКЕГӘ ТИСӘҢ...

Диләрә Мөхәммәтшина табылдык чемодан белән республика бәйгесендә беренче урынны алган

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 6 (29166) | Чәршәмбе | 17 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

БУ БИТ МИНЕМ АВЫЛ!

Яшәеш

Чебиләрне көзен санасалар, авылларда хисапны ел башында тоталар. Февральгә кадәр сузылачак җыелышларда узган елга йомгак ясап, агымдагысына планнар барлана. Авылы, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен янып-көеп яшәгән кеше мондый җыелышлардан читтә калмаска тырыша гадәттә. Хәер, замана уңайлыклары җыеннарга да үз яңалыкларын кертә.

Ел ахырында авыл кешеләре үзара салым җыю буенча җыелып, үз фикерләрен әйткән иде инде. Хәзер исә җирлек башлыклары узган елга нәтиҗә ясый.

– Безнең җирлектә авыл җыеннары февраль башында узачак. Елга нәтиҗә ясау башлыча шул үзара салым акчасына эшләгән эшләрне күрсәтү, сөйләп бирүгә кайтып кала инде ул, чөнки башка программаларда катнашып акча алу бик авыр хәзер, – ди Яшел Үзән районының Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы Фирая Фәйзуллина. – Ә менә үзара салымга авылларда бик күп эшләр башкарылды.

Исәпләре – быел да сынатмаска. Олы Җәке авыл җирлегенә биш авыл керә. Алар арасында саллы акчаны Никольский авылы халкы җыя: һәркайсыннан 8әр мең сум. Дөрес, халкы да аз. Егерме генә кеше теркәлгән. Үтәнгеш авылында да унөч кеше генә яши. Узган ел 3000 сум җыйган булсалар, быел 500әр сумнан гына килешкәннәр.

– Җыелган акчалары бик аз була инде. Әле узган ел 3 меңнән җыелгач, юлларын карата алган идек. 2014 елда бер казанга йөзәр сум салудан башлаган идек. Әле анда да халыктан акча җыю авыр булды, хәзер эшләр күренә башлагач, аңлап җыялар. Бер авылдан – 500 сум, калган икесендә 2000 һәм 2500 сумнан җыелышалар. Аларда зиратларны карап, агачларын кистереп, коймаларын яңартырга кирәк. Гомумән алганда, юллар каралды. Авыл халкын иң борчыган мәсьәлә шул иде.

Билгеле булганча, республикада үзара салым программасы 2012 елдан бирле эшли. Татарстан муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясенең матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, шушы вакыт эчендә халык үз авылларын карап тоту өчен 2,4 млрд сум акча керткән, аңа каршы бюджеттан 9 млрд сумнан күбрәк акча әйләнеп кайткан. 2023 елда гына да 250 чакрым юл төзелгән, 120 чакрым су челтәрләре яңартылган. Үзгәрешләргә килгәндә, быелдан, программа башланганда ук каралганча, программа бары тик авыллар һәм бистәләр өчен генә эшләячәк. Ягъни шәһәрләр һәм район үзәкләре моннан соң үзара салым җыюда катнашмаячак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шушы еллар эчендә саннар гына түгел, үзара салымга карата кешеләрнең карашлары да үзгәрде. Әйтик, 2015 елда халыкның 87,9 проценты, 2016 елда – 86,6, 2017 елда – 86,9, 2018 елда – 82, 2019 елда – 82,9, 2020 елда – 81,9, 2021 елда 91,3 проценты үзара салым акчасы җыюда катнашкан.

> Авыл зурмы ул, кечкенәме – шунда туып-үскән кеше өчен ул бер үк дәрәҗәдә якын, газиз булып кала, – ди Мөслимдә яшәүче Алмаз Сабирҗанов. – Хәзер авыл халкы бу салымның кирәклеген аңлый, һәрхәлдә, күп өлеше шулай. Авыл юллары кыш буе ачылып тора, багана утлары эшли, чүпне вакытында алып китәләр, һәр йортка су керде, кыскасы, шәһәр уңайлыклары белән бер дәрәҗәдә. Бу, әлбәттә, халыкка ошый.

Мисалга ул үз туган авылын китерде. Бүген Иске Сәеттә бик аз кеше яши икән. Шул исәптән Алмазның әнисе дә.

– Безнең урамга Советлар Союзы чорында су торбасы сузылмый калган. Авыл кечкенә, урамда өч кенә йорт, яшәүчеләре башлыча пенсия яшендәгеләр. Күп еллар дустанә мөнәсәбәттә гомер иткәнгә, күршеләр белән киңәш-табыш итеп, программада катнашырга булдык. Унҗиде мең сумнан артык акча җыеп, ике йөз метр су торбасы сузуга ирештек. Ниһаять, урамыбыз сулы булды. Үзебез монда тормасак та, акчаның күпчелек өлешен үзем бирдем, документ эшләре белән абыем йөрде, чөнки монда безнең әниебез яши. Бу бит үзебез уйнап үскән урам, кешеләре дә туганнар кебек якын. Мөмкинлекләр бар икән, алардан файдаланырга кирәк, – ди Алмаз.

Биектау районының Алан-Бәксәр авыл җирлегендә исә җыеннар 24 гыйнвардан башлана. Аның башлыгы Зөһрә Гарифуллина әйтүенчә, үзара салым, эшләнгән эшләр ел дәвамында халыкның күз алдында, җыеннарда аларны тагын бер тапкыр искә төшереп, башка мәсьәләләр буенча да фикер алышалар.

– Бездә халык күп булмагач, үзара салым акчасы артык күп җыелмый. Ләкин аларын да бәрәкәтле итеп, кирәкле эшләргә тотарга тырышабыз. Авыл халкы өчен зур чаган агачларын кисү бик мөһим иде, аны башкарып чыктык. Моннан тыш, узган ел чүп контейнерлары мәйданнарын куйдык, быел да бу эшне дәвам итәчәкбез. Парк ясап, балалар мәйданчыкларын эшләп куярга ниятлибез. Программага да керә алдык. Җыеннарда пай җирләре өчен дә хисап тоталар. Үзем исә халыкка кирәкле мәгълүмат, тормышчан, халыкчан мәгълүмат бирергә тырышам. Чөнки аларга саннар кызык түгел. Элеккеге кебек җыелышларга зал тутырып килүләр дә, кызу бәхәсләр дә, сораулар яудырулар да юк инде хәзер. Чөнки тормыш телефоннарда кайный. Көнүзәк мәсьәләләрне авыл группаларында көне, сәгате белән җиткерәләр. Шуңа күрә күпчелеге җыелышка кадәр үк хәл ителә, – ди Зөһрә Гарифуллина.

Сак булыгыз, егетләр!

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзенең телеграм-каналында, республика министрларының аккаунтларын «вату» очраклары ешаю сәбәпле, уяу булырга өндәгән.

«Телефоннарыгызны карабрак йөрегез, егетләр!» – дип язган Татарстан Рәисе. Шул ук вакытта ул, үзенең стационар телефоннан сөйләшү мизгелләре сурәтләнгән елмаюлы фотосын урнаштырып, сүзне матур гына икенчегә боргандай итеп куйган.

Интернет чыганаклар хәбәрләренә караганда, сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченконың, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаровның аккаунтларын «ватканнар». Шул сәбәпле Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин үзенең телеграм-каналында мессенджердан файдалану буенча киңәшләр биргән.

Акча арта

1 февральдән беренче балага ана капиталы күләме 630,4 мең сумга җитә. Россия Хөкүмәте хәбәр иткәнчә, гаилә беренче баласына инде капитал алса, икенчесе дөньяга килгәч, аңа тагын 202,6 мең сум өстәп түләнеләчәк.

Шулай итеп, икенче балага ана капиталы 833 мең сум тәшкил итәчәк.

Исегезгә төшерәбез: акчаны торак шартларын яхшырту, баланы укыту яки ана кеше пенсиясенең тупланма өлешен булдыру кебек билгеле бер максатларга гына тотарга мөмкин. Шул ук вакытта капиталны алуның үзенчәлекләре һәм таләпләре бар.

5 еллык йомгак

Биш ел эчендә Татарстанда илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга 180,9 миллиард сум юлланган. Республиканың Икътисад министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, бу максатка төбәк казнасыннан 50,7 миллиард сум тотылган.

Шулай итеп, 2019 елдан бирле бездә 77 спорт корылмасы калкып чыккан. Болар – спорт сарайлары, ГТО мәйданчыклары, балаларның уен мәйданчыклары һәм башка шундый корылмалар. Шул ук вакытта республикада балалар бакчалары белән тәэмин итү 100 процентка җиткән. Бүгенгә 5–18 яшькә кадәрге балаларның 80 проценттан артыграгы өстәмә белем алу мөмкинлегенә ия.

Моннан тыш төбәктә 255 сәламәтлек саклау оешмасы бинасы яңартылган. Болар – фельдшер-акушерлык пунктлары, сырхауханәләр һәм амбулатория учреждениеләре.

Исегезгә төшерәбез: быел республикада «Сәламәтлек» илкүләм проекты кысасында 128 медицина объектын төзү һәм төзекләндерү каралган. Төбәктә 2 сырхауханә, гомумпрактика табибы үзәге һәм 20 фельдшер-акушерлык пункты пәйда булачак. Тагын 28 ФАП республика акчасына төзеләчәк. Шулай ук илкүләм проект кысасында 82 ФАП һәм 23 медицина оешмасы бинасын капиталь төзекләндерү күздә тотыла.

961 сырхау

8–14 гыйнвар чорында Татарстанда 961 кешенең коронавирус йоктыруы ачыкланган. «Объясняем.РФ» Хөкүмәт порталы хәбәренә караганда, яңа елның икенче атнасында ковид иярткән 111 сырхауны хастаханәгә озатырга туры килгән. 1125 кеше савыккан. Үлем-китем очраклары теркәлмәгән.

Гомумән, ил буенча хастаханәгә салу очраклары алдагы атнадагыга караганда 21,4 процентка арткан. 54 төбәктә шундый хәл күзәтелгән.

Сайлау – 2024

Йөрәк кушканны кул яза

Россия Президентына Владимир Путин кандидатурасын хуплап имза җыю эше дәвам итә. Әлеге эш Татарстандагы сәүдә үзәкләре, кандидатның төбәк штабы, Халык фронтының төбәк бүлекчәләрендә оештырылган. Имза җыю гыйнвар азагына кадәр дәвам итәчәк әле. Бердәм имза җыю көнендә, ягъни 16 гыйнварда республика депутатлары да ил киләчәген хәл итәчәк чарада катнашты.

– Владимир Путин кандидатурасын хуплап имза җыюның бердәм көне Татарстан районнарындагы 43 халыкны кабул итү бүлекчәләрендә, Казанда тагын 7 урында уза, – диде Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Бердәм Россия» партиясенең төбәк иҗтимагый кабул итү үзәге җитәкчесе Камил Садриев. – Монда йөрәк кушуы буенча гына киләләр. Ничә кеше килер дип алдан план кую кирәкми дә. Менә мин дә иртән тордым, йөрәгем кушуы буенча килдем, үз фикеремне белдердем. 16 гыйнварда 16 нчы регионда яшәүченең имза куюы символик мәгънәгә дә ия әле ул!

Иртәнге сәгатьләрдә Марат Галиев, Камил Нугаев, Мәгъзүм Сәләхов, Леонид Якунин кебек депутатлар да Владимир Путин кандидатурасын хуплап имза калдырырга дип штабка килеп китте.

– Дәүләт җитәкчесе алып барган сәясәтне тулысынча хуплыйм, – диде Леонид Якунин. – Аның ярдәмендә ил, ниһаять, Көнбатышка бәйлелектән чыга башлады. Мондый зур илгә башка лидер күрмим.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да бу эштән читтә калмады. Парламент җитәкчесенең бу эшкә ике минут вакыты киткәндер. «Тәмам! Гражданлык бурычын үтәдем!» – диде имзасын куеп, эшен бетергәч Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе сүзләренчә, гамәлдәге ил башлыгы кандидатурасын күпчелек хуплый.

– Аңлашу да бар, җаваплылык та бар. Халык та моны белә. Илдә җиңел вакытлар түгел. Борчыган мәсьәләләр күп. Без партия аша Владимир Путин кандидатурасын хуплап чыктык. Халкыбыз да аңлый: яңа кеше Президент вазыйфасына килеп, бу эшкә керешкәнче, вакыт әрәм иткәнче, күп нәрсәне югалтачакбыз, – диде ул.

Имза җыю, аңлату эшендә яшьләр дә актив. «Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе» төбәк штабы җитәкчесе Руслан Шиһабетдинов әйтүенчә, яшьләр мондый сәяси вакыйгалардан читтә калмый.

– Безгә илнең нинди юлдан баруы, әлбәттә, бик мөһим. Безгә барыбер түгел. Волонтер буларак без Владимир Путин кандидатурасын хуплавыбызны күрсәтәбез, – диде ул. – Имзаларны җыярга, тупларга ярдәм итәбез. Бу эш штаб кысасында гына бармый.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Бадма БАШАНКАЕВ, Дәүләт Думасының Сәламәтлек саклау комитеты рәисе:

Россиялеләр өчен медицина ярдәме сыйфатын күтәрүгә игътибарны арттырырга кирәк. Моңа күчмә даруханә пунктлары турындагы закон проекты ярдәм итә ала. Ул авыл халкын, бигрәк тә авыллардагы өлкәннәрне кирәкле дарулар белән тәэмин итүне күздә тота.

(«Парламентская газета»дан)

ГАДЖЕТЛАРГА БӘЙЛЕЛЕК

Россиядә яшәүчеләр көн саен уртача алганда өч-дүрт сәгать вакытын телефонда үткәрә. Бу хакта «Бери Заряд!» оештырган сораштыру нәтиҗәләре сөйли.

ТЕЛЕФОНДА НӘРСӘ ЭШЛИСЕЗ?

- 43% – социаль челтәрләр алып бара, аралаша (күпчелек – хатын-кызлар)
- 21% – эшли
- 15% – видеоконтент карый
- 10% – уеннар уйный
- 5% – аудиокитаплар тыңлый яисә укый

4 МИЛЛИОН

Узган ел республикага әнә шулкадәр турист килгән. Быел тагын да күбрәккә өметләнәләр

> 2

РАЗИФ ХАФИЗОВ:

«Очраклы гына газета кулыма килеп керде дә, әллә нәрсә булды: йөрәгем кысылып куйды»

> 3

ТАРИХ = КОМЕДИЯ?

Татар киносына әлениләр күрәсе?

> 4

ИСКЕГӘ ТИСӘҢ...

Диләрә Мөхәммәтшина табылдык чемодан белән республика бәйгесендә беренче урынны алган

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 6 (29166) | Чәршәмбе | 17 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

БУ БИТ МИНЕМ АВЫЛ!

Яшәеш

Чебиләрне көзен санасалар, авылларда хисапны ел башында тоталар. Февральгә кадәр сузылачак җыелышларда узган елга йомгак ясап, агымдагысына планнар барлана. Авылы, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен янып-көеп яшәгән кеше мондый җыелышлардан читтә калмаска тырыша гадәттә. Хәер, замана уңайлыклары җыеннарга да үз яңалыкларын кертә.

Ел ахырында авыл кешеләре үзара салым җыю буенча җыелып, үз фикерләрен әйткән иде инде. Хәзер исә җирлек башлыклары узган елга нәтиҗә ясый.

– Безнең җирлектә авыл җыеннары февраль башында узачак. Елга нәтиҗә ясау башлыча шул үзара салым акчасына эшләгән эшләрне күрсәтү, сөйләп бирүгә кайтып кала инде ул, чөнки башка программаларда катнашып акча алу бик авыр хәзер, – ди Яшел Үзән районының Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы Фирая Фәйзуллина. – Ә менә үзара салымга авылларда бик күп эшләр башкарылды.

Исәпләре – быел да сынатмаска. Олы Җәке авыл җирлегенә биш авыл керә. Алар арасында саллы акчаны Никольский авылы халкы җыя: һәркайсыннан 8әр мең сум. Дөрес, халкы да аз. Егерме генә кеше теркәлгән. Үтәнгеш авылында да унөч кеше генә яши. Узган ел 3000 сум җыйган булсалар, быел 500әр сумнан гына килешкәннәр.

– Җыелган акчалары бик аз була инде. Әле узган ел 3 меңнән җыелгач, юлларын карата алган идек. 2014 елда бер казанга йөзәр сум салудан башлаган идек. Әле анда да халыктан акча җыю авыр булды, хәзер эшләр күренә башлагач, аңлап җыялар. Бер авылдан – 500 сум, калган икесендә 2000 һәм 2500 сумнан җыелышалар. Аларда зиратларны карап, агачларын кистереп, коймаларын яңартырга кирәк. Гомумән алганда, юллар каралды. Авыл халкын иң борчыган мәсьәлә шул иде.

Билгеле булганча, республикада үзара салым программасы 2012 елдан бирле эшли. Татарстан муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясенең матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, шушы вакыт эчендә халык үз авылларын карап тоту өчен 2,4 млрд сум акча керткән, аңа каршы бюджеттан 9 млрд сумнан күбрәк акча әйләнеп кайткан. 2023 елда гына да 250 чакрым юл төзелгән, 120 чакрым су челтәрләре яңартылган. Үзгәрешләргә килгәндә, быелдан, программа башланганда ук каралганча, программа бары тик авыллар һәм бистәләр өчен генә эшләячәк. Ягъни шәһәрләр һәм район үзәкләре моннан соң үзара салым җыюда катнашмаячак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шушы еллар эчендә саннар гына түгел, үзара салымга карата кешеләрнең карашлары да үзгәрде. Әйтик, 2015 елда халыкның 87,9 проценты, 2016 елда – 86,6, 2017 елда – 86,9, 2018 елда – 82, 2019 елда – 82,9, 2020 елда – 81,9, 2021 елда 91,3 проценты үзара салым акчасы җыюда катнашкан.

> Авыл зурмы ул, кечкенәме – шунда туып-үскән кеше өчен ул бер үк дәрәҗәдә якын, газиз булып кала, – ди Мөслимдә яшәүче Алмаз Сабирҗанов. – Хәзер авыл халкы бу салымның кирәклеген аңлый, һәрхәлдә, күп өлеше шулай. Авыл юллары кыш буе ачылып тора, багана утлары эшли, чүпне вакытында алып китәләр, һәр йортка су керде, кыскасы, шәһәр уңайлыклары белән бер дәрәҗәдә. Бу, әлбәттә, халыкка ошый.

Мисалга ул үз туган авылын китерде. Бүген Иске Сәеттә бик аз кеше яши икән. Шул исәптән Алмазның әнисе дә.

– Безнең урамга Советлар Союзы чорында су торбасы сузылмый калган. Авыл кечкенә, урамда өч кенә йорт, яшәүчеләре башлыча пенсия яшендәгеләр. Күп еллар дустанә мөнәсәбәттә гомер иткәнгә, күршеләр белән киңәш-табыш итеп, программада катнашырга булдык. Унҗиде мең сумнан артык акча җыеп, ике йөз метр су торбасы сузуга ирештек. Ниһаять, урамыбыз сулы булды. Үзебез монда тормасак та, акчаның күпчелек өлешен үзем бирдем, документ эшләре белән абыем йөрде, чөнки монда безнең әниебез яши. Бу бит үзебез уйнап үскән урам, кешеләре дә туганнар кебек якын. Мөмкинлекләр бар икән, алардан файдаланырга кирәк, – ди Алмаз.

Биектау районының Алан-Бәксәр авыл җирлегендә исә җыеннар 24 гыйнвардан башлана. Аның башлыгы Зөһрә Гарифуллина әйтүенчә, үзара салым, эшләнгән эшләр ел дәвамында халыкның күз алдында, җыеннарда аларны тагын бер тапкыр искә төшереп, башка мәсьәләләр буенча да фикер алышалар.

– Бездә халык күп булмагач, үзара салым акчасы артык күп җыелмый. Ләкин аларын да бәрәкәтле итеп, кирәкле эшләргә тотарга тырышабыз. Авыл халкы өчен зур чаган агачларын кисү бик мөһим иде, аны башкарып чыктык. Моннан тыш, узган ел чүп контейнерлары мәйданнарын куйдык, быел да бу эшне дәвам итәчәкбез. Парк ясап, балалар мәйданчыкларын эшләп куярга ниятлибез. Программага да кердк алдык. Җыеннарда пай җирләре өчен дә хисап тоталар. Үзем исә халыкка кирәкле мәгълүмат, тормышчан, халыкчан мәгълүмат бирергә тырышам. Чөнки аларга саннар кызык түгел. Элеккеге кебек җыелышларга зал тутырып килүләр дә, кызу бәхәсләр дә, сораулар яудырулар да юк инде хәзер. Чөнки тормыш телефоннарда кайный. Көнүзәк мәсьәләләрне авыл группаларында көне, сәгате белән җиткерәләр. Шуңа күрә күпчелеге җыелышка кадәр үк хәл ителә, – ди Зөһрә Гарифуллина.

Сак булыгыз, егетләр!

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзенең телеграм-каналында, республика министрларының аккаунтларын «вату» очраклары ешаю сәбәпле, уяу булырга өндәгән.

«Телефоннарыгызны карабрак йөрегез, егетләр!» – дип язган Татарстан Рәисе. Шул ук вакытта ул, үзенең стационар телефоннан сөйләшү мизгелләре сурәтләнгән елмаюлы фотосын урнаштырып, сүзне матур гына икенчегә боргандай итеп куйган.

Интернет чыганаклар хәбәрләренә караганда, сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченконың, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаровның аккаунтларын «ватканнар». Шул сәбәпле Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин үзенең телеграм-каналында мессенджердан файдалану буенча киңәшләр биргән.

Акча арта

1 февральдән беренче балага ана капиталы күләме 630,4 мең сумга җитә. Россия Хөкүмәте хәбәр иткәнчә, гаилә беренче баласына инде капитал алса, икенчесе дөньяга килгәч, аңа тагын 202,6 мең сум өстәп түләнеләчәк.

Шулай итеп, икенче балага ана капиталы 833 мең сум тәшкил итәчәк.

Исегезгә төшерәбез: акчаны торак шартларын яхшырту, баланы укыту яки ана кеше пенсиясенең тупланма өлешен булдыру кебек билгеле бер максатларга гына тотарга мөмкин. Шул ук вакытта капиталны алуның үзенчәлекләре һәм таләпләре бар.

5 еллык йомгак

Биш ел эчендә Татарстанда илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга 180,9 миллиард сум юлланган. Республиканың Икътисад министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, бу максатка төбәк казнасыннан 50,7 миллиард сум тотылган.

Шулай итеп, 2019 елдан бирле бездә 77 спорт корылмасы калкып чыккан. Болар – спорт сарайлары, ГТО мәйданчыклары, балаларның уен мәйданчыклары һәм башка шундый корылмалар. Шул ук вакытта республикада балалар бакчалары белән тәэмин итү 100 процентка җиткән. Бүгенгә 5–18 яшькә кадәрге балаларның 80 процентан артыграгы өстәмә белем алу мөмкинлегенә ия.

Моннан тыш төбәктә 255 сәламәтлек саклау оешмасы бинасы яңартылган. Болар – фельдшер-акушерлык пунктлары, сырхауханәләр һәм амбулатория учреждениеләре.

Исегезгә төшерәбез: быел республикада «Сәламәтлек» илкүләм проекты кысасында 128 медицина объектын төзү һәм төзекләндерү каралган. Төбәктә 2 сырхауханә, гомумпрактика табибы үзәге һәм 20 фельдшер-акушерлык пункты пәйда булачак. Тагын 28 ФАП республика акчасына төзеләчәк. Шулай ук илкүләм проект кысасында 82 ФАП һәм 23 медицина оешмасы бинасын капиталь төзекләндерү күздә тотыла.

961 сырхау

8–14 гыйнвар чорында Татарстанда 961 кешенең коронавирус йоктыруы ачыкланган. «Объясняем.РФ» Хөкүмәт порталы хәбәренә караганда, яңа елның икенче атнасында ковид иярткән 111 сырхауны хастаханәгә озатырга туры килгән. 1125 кеше савыккан. Үлем-китем очраклары теркәлмәгән.

Гомумән, ил буенча хастаханәгә салу очраклары алдагы атнадагыга караганда 21,4 процентка арткан. 54 төбәктә шундый хәл күзәтелгән.

Сайлау – 2024

Йөрәк кушканны кул яза

Россия Президентына Владимир Путин кандидатурасын хуплап имза җыю эше дәвам итә. Әлеге эш Татарстандагы сәүдә үзәкләре, кандидатның төбәк штабы, Халык фронтының төбәк бүлекчәләрендә оештырылган. Имза җыю гыйнвар азагына кадәр дәвам итәчәк әле. Бердәм имза җыю көнендә, ягъни 16 гыйнварда республика депутатлары да ил киләчәген хәл итәчәк чарада катнашты.

– Владимир Путин кандидатурасын хуплап имза җыюның бердәм көне Татарстан районнарындагы 43 халыкны кабул итү бүлекчәләрендә, Казанда тагын 7 урында уза, – диде Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Бердәм Россия» партиясенең төбәк иҗтимагый кабул итү үзәге җитәкчесе Камил Садриев. – Монда йөрәк кушуы буенча гына киләләр. Ничә кеше килер дип алдан план кую кирәкми дә. Менә мин дә иртән тордым, йөрәгем кушуы буенча килдем, үз фикеремне белдердем. 16 гыйнварда 16 нчы регионда яшәүченең имза куюы символик мәгънәгә дә ия әле ул!

Иртәнге сәгатьләрдә Марат Галиев, Камил Нугаев, Мәгъзүм Сәләхов, Леонид Якунин кебек депутатлар да Владимир Путин кандидатурасын хуплап имза калдырырга дип штабка килеп китте.

– Дәүләт җитәкчесе алып барган сәясәтне тулысынча хуплыйм, – диде Леонид Якунин. – Аның ярдәмендә ил, ниһаять, Көнбатышка бәйлелектән чыга башлады. Мондый зур илгә башка лидер күрмим.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да бу эштән читтә калмады. Парламент җитәкчесенең бу эшкә ике минут вакыты киткәндер. «Тәмам! Гражданлык бурычын үтәдем!» – диде имзасын куеп, эшен бетергәч Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе сүзләренчә, гамәлдәге ил башлыгы кандидатурасын күпчелек хуплый.

– Аңлашу да бар, җаваплылык та бар. Халык та моны белә. Илдә җиңел вакытлар түгел. Борчыган мәсьәләләр күп. Без партия аша Владимир Путин кандидатурасын хуплап чыктык. Халкыбыз да аңлый: яңа кеше Президент вазыйфасына килеп, бу эшкә керешкәнче, вакыт әрәм иткәнче, күп нәрсәне югалтачакбыз, – диде ул.

Имза җыю, аңлату эшендә яшьләр дә актив. «Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе» төбәк штабы җитәкчесе Руслан Шиһабетдинов әйтүенчә, яшьләр мондый сәяси вакыйгалардан читтә калмый.

– Безгә илнең нинди юлдан баруы, әлбәттә, бик мөһим. Безгә барыбер түгел. Волонтер буларак без Владимир Путин кандидатурасын хуплавыбызны күрсәтәбез, – диде ул. – Имзаларны җыярга, тупларга ярдәм итәбез. Бу эш штаб кысасында гына бармый.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Бадма БАШАНКАЕВ, Дәүләт Думасының Сәламәтлек саклау комитеты рәисе:

Россиялеләр өчен медицина ярдәме сыйфатын күтәрүгә игътибарны арттырырга кирәк. Моңа күчмә даруханә пунктлары турындагы закон проекты ярдәм итә ала. Ул авыл халкын, бигрәк тә авыллардагы өлкәннәрне кирәкле дарулар белән тәэмин итүне күздә тота.

(«Парламентская газета»дан)

ГАДЖЕТЛАРГА БӘЙЛЕЛЕК

Россиядә яшәүчеләр көн саен уртача алганда өч-дүрт сәгать вакытын телефонда үткәрә. Бу хакта «Бери Заряд!» оештырган сораштыру нәтиҗәләре сөйли.

ТЕЛЕФОНДА НӘРСӘ ЭШЛИСЕЗ?

43% – социаль челтәрләр алып бара, аралаша (күпчелек – хатын-кызлар)
21% – эшли
15% – видеоконтент карый
10% – уеннар уйный
5% – аудиокитаплар тыңлый яисә укый



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЯКЫН КӨНЧЫГЫШ УТЛЫ ТАБАДА

2024 елның кайнар вакыйгалары үсешен дәвам итә. Вазгыять, көтелгәнчә, Якын Көнчыгыш төбәгендә киеренкеләнә. Көнбатыш коалициянең Йәмәнне бомбага тотуы бернинди дә нәтиҗә бирмәде диярлек. Илнең коралды көчләре Кызыл диңгездә йөзүче корабларга һөҗүмен туктатмады. Ул төбәктән без алган хәбәрләр шуны дәлилли. Британиянең диңгез куркынычсызлыгы агентлыгы Аден култыгындагы Америка сәүдә корабына ракета тиюен раслады. Американнар, кораб зыян күрмәде, дип ышандырсалар да, чынлыкта, ул кире борылган. АКШ эсминецы DDG-58 Laboonга ракета һөҗүме дә ясалды. Американнар, барлык ракеталар бәреп төшерелде, дип бара, йәмәнлеләр исә, 300 кешелек экипаждан торган бортка зыян килде, дигән мәгълүмат тарата.

Дүшәмбедән сишәмбегә каршы төндә Гыйрак Әрбәләсендәге Америка хәрби базасында һәм шәһәрдәге АКШ консуллыгы янында күпсанлы шартлау тавышлары ишетелә дигән хәбәр алынды. Иран революциясен саклаучылар корпусы Фатех-110 ракеталары белән аткан икән. Шул ук ракеталар Сүриягә дә очкан. Әрбәләдәге һава һөҗүменә каршы тору чаралары фарсы ракеталарын тота алмаган. Тәһран, Моссадның (Израиль разведкасы) шпион штабын юк иттек, дип бара. Вашингтон үзенең хәрби базалары бернинди дә зыян күрмәде дип белдерә. Әмма җирле халык, ракеталар тигәннән соң, базада детонация булуын һәм күпсанлы шартлаулар яңгыравын сөйли. Гыйрак матбугаты 5 америкалы солдат үтерелде дип яза. Илчелеккә яисә консуллыкка ату (ниндидер бер коралды террорчылар төркеме түгел, дәүләт һөҗүм итә бит) casus belli, ягъни сугыш башлауга сәбәп була ала. Әмма янкилар «тимәде, тисә дә, зыян салмады» дигән принцип белән масштаблы сугыш хәрәкәтләреннән сакланырлар, мөгаен.

Мисыр белән Израиль арасында сугыш ихтималлыгы үсә. Израиль Мисыр белән Газзә арасындагы чикне кулга төшерергә тели. Бу – Мисыр территориясе. Каһирә аны кызыл сызык дип атады һәм Тель-Авив коралды көчләрен кулланса, сугышка кушылачагын әйтте. Сишәмбегә каршы төндә Мисырдан егермеләп коралды кеше Израиль кулы астындагы җирләргә үтеп керде һәм бәрелеш булды.

Европада да тыныч түгел. Франциядә «Патриотлар» партиясен яклаган митинг булып узды. Партиянең лидеры Флориан Филиппо ЕС флагын ертты, НАТО альянсын юк итәргә чакырды. Көнбатышны Өченче Бөтендөнья сугышы утын кабызырга хыялланууда гаепләде. Германиядә ультрауңнар (неонацистлар) партиясенең популярлыгы үсә һәм сайлауларда хакимияткә килү ихтималлыгы арта.

Бер кызыклы икътисад яңалыгы: АКШта Россия үрнәгендә йомырка дефициты пәйда булды.

Россиядә

САНКЦИЯЛӘР БЕНЗИНСЫЗ КАЛДЫРМАСМЫ?

Дөньякүләм турбулентлык Россия икътисадына да үз эзен сала. Кызыл диңгездәге хәлләр нефть бәясен югарыга күтәреп, Россия өчен өстәмә табыш бирергә ихтимал иде. Әмма, бердән, нефть төягән Россия танкерларына да хәзер Африканы әйләнеп узарга туры килә. Йәмәнлеләр Мәскәү белән яхшы мөнәсәбәттә булуга һәм без озаткан корабларга тимәскә вәгъдә бирүгә карамастан, бер танкерга ялгыш аттылар. Юлның озынаюы транспорт чыгымнарын арттыра, табышны киметә. Bloomberg агентлыгы, нефть бәясе, геосәяси киеренкелеккә карамастан, түбәнгә китәргә ихтимал, дип фаразлый. Фараз чынга ашса, Россия бюджеты өчен өстәмә проблемалар туачак. Муллык фонды төпсез түгел, киләсе ел башына сәмән төгәлләнергә мөмкин.

Әле бәяләр яхшы гына торганда да проблемалар калкып чыга. Федераль хөкүмәт үткән ел мазутны җылылык станцияләрендә ягып, нефть эшкәртү заводларын коткарган иде. Башланып килгән бензин кытлыгы шуның белән төгәлләнде. Әмма быел яңадан калкып чыгарга азаплана. Бу юлы нефть эшкәртү предприятиеләрен бүтән проблема эзәрлекли. Түбән Новгородтагы «ЛУКОЙЛ» нефть эшкәртү заводы авария нәтиҗәсендә бензин җитештерүне кискен киметте. Башта бу хакта «Интерфакс» агентлыгы хәбәр итте, Энергетика министрлыгы раслады. Заводтагы авария исә чит илдә җитештерелгән компрессор җиһазының ватылуына бәйле. Ул җиһаз хәзер Россиягә сатылмый, аңа тиңне бездә җитештермиләр. Көнбатыш санкцияләре нәкъ менә шулай озак вакытлы һәм акрын тәэсир итү өчен кертелделәр дә инде. Җиһазның төрдәше Кытайда да табылмаса яисә көнбатышлылар яшереп кенә безгә үзләре үк сатмаса, заводка озак вакытка җитештерүне киметергә туры киләчәк. Башка заводларда да шулай ук импорт җиһазлар кулланыла. Алар берәм-берәм сафтан чыкса, хәл авыраерга мөмкин. Әлегә кытайлар ярдәмгә килер дигән өмет саклана.

Агымдагы вазгыятьтә мәсьәләне бензин экспортын чикләп хәл итәрләр. Федераль хөкүмәт шундый карар әзерли дигән сүз бар, әмма ул рәсми рәвештә әлегә расланмады.

Коммуналь хуҗалыкта масштаблы аварияләр сериясе дәвам итә. Исемлектә яңа шәһәрләр пәйда була. Монысының сәбәбен күп кеше яшәүче йортларның артык күп төзелүенә бәйлиләр. Ни өчен проблеманың быел гына баш калкытуын аңлап булмый. «Человейник» дип йөртелгән йортлар күптән бар бит инде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

КИЛДЕ-КИТТЕ БУЛМАСЫН

Нәтиҗә

Узган ел Татарстанга килгән кунаклар саны республикада яшәүчеләр саны белән тигезләшкән – безгә җәмгысы 4 млн кунак килгән. Шулай итеп, туристлар саны тарихи чикне узган. Аларны Татарстан нәрсәсе белән җәлеп итә һәм тагын ничек җәлеп итәчәк? Санны да, сыйфатны да ничек арттырырга? Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитетының киңәйтелгән коллегия утырышында әнә шул һәм башка сорауларга җавап эзләдек.

«Статистика белән бәхәсләшеп булмый: Татарстан, чыннан да, туристлар иң күп килә торган Россия төбәкләре исемлегенә керә», – ди Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов. Бу кадәр кешенең күңелен күрү өчен шактый тырышырга кирәк, билгеле. Коллегия утырышында тырышлык нәтиҗәләре дә, җитешсез яклар да, киләчәккә планнар да яңгырады.

Нияләр эшләнгән?

Елдагыча, Туризм комитеты «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проектында катнашкан. Аның кысасында Татарстанда биш юнәлеш буенча эш башкарылган, 817,4 млн сум акча тотылган. Әйтик, шифаханәләр, глэмпинглар тирәсендә пляжлар ачу, шәһәр пляжларын төзекләндерү максатыннан 22 проект күрсәтелгән. Бу елгы су коену сезонында 13 яңа пляж ачылыр дип көтелә.

Әлеге илкүләм проектның инде шактый популяр булган шәһәр читендәге ял итү объектларына да ярдәме тигән. 2023 елда яңа 18 объект ачылган, быел республика районнарында тагын 13 ял итү урыны барлыкка киләчәк. Саннарга күз салсаң, узган ел глэмпинг ише урыннарда 70 меңләп кеше ял иткән. 2022 елга караганда 30 процентка артык бу. Аларда ял итүнең бәяләрен һәм ял итүчеләрнең санын чагыштырып карасаң, алай начар яшәмибез икән әле…

Сан да, сыйфат та

Кунакларыбыз күп булгач, эше дә күп, дигән идек инде. Проблемалар да юк түгел, алар аеруча туристлар күпләп килә торган чорларда калкып чыга. Әйтик, беренчедән, номер фондының җитмәве, ягъни туристлар өчен яшәү урыннарының аз булуы. Икенчедән, кадрлар, персонал җитмәү. Өченчедән, хезмәт күрсәтү сыйфаты. Аеруча экскурсияләргә кагыла бу. Узган ел тарихи вакыйгалар турында дөрес сөйләмәгән экскурсоводлардан зарланучылар шактый булган.

Сыйфатка бәйле җитешсезлекләрне Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева да атады.

Татарстанда туризм – саннарда

3,2 тәүлек – Татарстанга килгән туристның кунак булу вакыты.
22,4 мең – Татарстанга килгән туристның уртача чыгымнары.
88 млрд сум – 2023 елда туризм тармагындагы әйләнеше.
55 млрд сум – 2023 елның 10 аенда җәмәгать туклануы өлкәсендәге әйләнеше.
>5 млн кеше – Казан аэропорты хезмәт күрсәткән кеше саны.

– Туристлар санын арттырырга кирәк. Ә ул сан туристларга күрсәтелә торган хезмәт сыйфатын яхшырткан очракта арта. Номер фонды, туклану, экскурсияләр – барысының да сыйфатына карата сораулар бар әле. Бүген безнең бурыч – килгән кунакларыбызны таң калдырып, тагын күп тапкыр килү теләге уяту, – диде ул.

Сыйфатны яхшырту өчен яхшы белгечләр кирәк. Ләйлә Фазлыева туризм тармагына белгечләр әзерләүгә аерым игътибар бирергә кушты.

Нияләр эшлисе?

Ә 2024 елга комитет үз алдына җиде бурыч куйган. Әллә ни яңалыклар юк. Элеккечә «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проектында актив катнашырга, Татарстан районнарында туристик үзәкләр булдырырга. Әле бит Казанда узачак зур чараларны – «Киләчәк уеннары»н, «Россия – Ислам дөньясы» форумын, «Kazan Digital Week» форумын, «БРИКС уеннары»н матур гына үткәреп җибәрергә кирәк.

– Моннан тыш, комитет алдына «Бөек Идел юлы» проектын үстерү, киңәйтү, «Казан марина» проекты өчен инфраструктура булдыру, автосәяхәтчеләр өчен шартлар тудыру бурычы да куела, – диде комитет рәисе.

Коллегия утырышында Татарстан Фәннәр академиясе рәисе Рифкать Миңнеханов та республикада игълан ителгән Фәнни-технологик үсеш елына ниятләре белән уртаклашты. Фән белән туризмны бәйләп, ике тәкъдим турында сөйләде ул. Беренчесе – Татарстан археология музееен булдыру. Икенчесе – Казан Кремлендә татар язма мирасына багышланган күргәзмә булдыру. «Туристлар күпләп йөри торган урында мондый фәнни-популяр мәйданчык булдыруның нинди нәтиҗәләр бирәчәген чамалыйсыздыр», – диде Миңнеханов.

ВОКЗАЛДА УТЫРЫП КАЛМЫЙК

Хөкүмәт йортында

Яңартылган электрон мәгариф яки халык телендәге edu.tatar.ru системасында татар теле программасына урын бармы? Электрон платформадан баш тартучылар аттестатсыз калмасмы? Татарстан Хөкүмәт йортында узган брифингта Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин әлеге һәм әти-әниләрне борчыган башка сорауларга ачыклык кертте.

Министрлар аңлатып үткәнчә, барлык әти-әниләр дә Россия Дәүләт хезмәте порталы аша теркәлергә һәм балаларына профильләр булдырырга тиеш. Бу – барлык әти-әниләр өчен дә яңалык. Әмма һәр адымны дөрес итеп башкарганда, кыенлыклар тумаячак. Туа икән, бу – вакытлыча гына. Айрат Хәйруллин белдергәнчә, хәзерге вакытта шәхси кабинетлары аша 150 мең әти-әни теркәлгән. Яңа платформага күчүгә бәйле 18 мең мөрәҗәгать кергән. Моңа кадәр укучыларның билгеләрен бутау, шул ук фамилиядәге башка баланы күрсәткән очраклар да булган. Болар барысы да хәл ителгән. Теркәлүгә бәйле мондый яки башка очраклар килеп чыкканда, ЗАГСка яки башка җиргә барырга кирәк. Системада проблема турында хәбәр бирү дә җитә.

Теркәлергә өлгермәгәннәр өчен Илсур Һадиуллин онлайн ата-аналар җыелышында, 22 гыйнвардан соң мәктәпләрдә барысына да логин-парольләр бирeләчәк, дип тынычландырган иде. Тик шуннан соң мәктәпләрдә: «Парольләр барлык укучыларга да түгел, сыйныфка икешәр генә биреләчәк», – дигән сүзләр дә ишетелә башлады. Янәсе, берьюлы күп кеше керсә, система чыдамаска мөмкин. Министрга янә: «Һәр балага да аерым логин-пароль бирелә, сыйныфка ике генә була алмый», – дип искәртергә туры килде.

Әти-әниләр арасында электрон мәшәкатьләргә түзмәүчеләр дә бар. «Безгә электрон көндәлек кирәкми», «Балаларның шәхси мәгълүматларын күрсәтергә теләмибез», – дип өчесе баш тарткан. Битараф калырга ярамый! Министр әйткәнчә, әлеге системада теркәлмәгәннәр хәтта аттестатсыз калырга мөмкин.

– Әлеге проблема 11 нче сыйныф укучыларына кагыла. БДИга теркәлү өчен ике атнадан азрак вакыт калып бара. Алар 1 февральгә кадәр нинди сынауларны сайлап алачагы турында гариза язарга тиеш. Шәхси мәгълүматларын күрсәтмәгәч, алар БДИга эләгә алмый һәм аттестатсыз калачак. Аттестат урынына, мәктәпне тәмамлаган, дигән белешмә генә биреләчәк, – диде Илсур Һадиуллин. – Әгәр син каядыр барырга җыенасың, әмма паспортыңны күрсәтмисең икән, беркая китә алмыйча вокзалда, аэропортта утырып калачаксың. Монда да шул ук хәл.

Шәхси мәгълүматны бирмәү исә электрон журналны туктатуга сәбәп була алмый.

> Электрон журналдан китеп, кәгазьгә кайту булмаячак. Кайтабыз икән, бу – укытучыга икеләтә эш арта дигән сүз. Электрон система укытучының, әти-әни, баланың эшен җиңеләйтү өчен эшләнде. Анда дәресләр, мөмкинлекләр дә күп. Теләсә кайсы яңалык җиңел генә керми. Электр миченнән керосин лампасына күчәргә теләмибез бит. Әйдәгез, барыбыздан да телефонны җыеп алыйк та, шәһәргә, авылга берне генә калдырыйк. Моңа беркем риза булмаячак, – диде Илсур Һадиуллин.

Элеккеге системада билге төзәтүдә кыенлыклар да бар иде. Хәзер моның өчен хәтта 21 көн вакыт бирелгән. Татар теленә дә урын бар. Хәзергә ике программа кертелгән. Болар – «Сәлам» белән Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре төзегән программа һәм дәреслекләр. Алга таба Татарстанда эшләгән дәреслекләрне, шулай ук физика, математика һәм башка фәннәрдән татарча дәресләр дә урнаштырылачак.

Сәрия МИФТАХОВА

ЙӨРӘК КУШКАННЫ КУЛ ЯЗА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Белешмә өчен

:: КЕМНӘР?

Хәзерге вакытта Россия Президентын сайлау кампаниясендә 11 кеше катнаша. Кандидатларның сигезен сәяси партияләр күрсәткән, ә өчесе үзен үзе тәкъдим иткән. Болар: Владимир Путин, Рада Русских, Анатолий Баташев (үз-үзен тәкъдим итүчеләр), Леонид Слуцкий (ЛДПР), Владислав Даванков («Новые люди»), Николай Харитонов (КПРФ), Сергей Малинкович («Коммунисты России»), Борис Надеждин («Гражданская инициатива»), Андрей Богданов («Российская партия свободы и справедливости»), Сергей Бабурин («Российский общенародный союз»), Ирина Свиридова («Демократическая партия России»). Шуларның өчесе – Леонид Слуцкий, Владислав Даванков һәм Николай Харитонов кандидат буларак рәсми рәвештә теркәлде инде.

:: КАЙЧАН?

Президент сайлау өч көн – 15, 16 һәм 17 мартта узачак.

:: КҮПМЕ?

Хәзерге вакытта бөтен ил буенча Россия Президентына кандидат Владимир Путинны хуплап 1,8 миллионнан артык имза җыелган.

Марафон

«Татарстанда начар эшләргә ярамый»

Республикада «Татарстан – казанышлар республикасы» автобус марафоны башланды. Марафон кысасында узучы фикер алышуларда сәясәтчеләр, министрлар, район хакимияте вәкилләре катнаша. Әлеге чара Татарстанның 29 районында булачак. Марафонда катнашучылар белән 15 гыйнварда Лаеш районында узган очрашуны күреп кайттык.

Атамасыннан аңлашылганча, марафон үзе Татарстанның казанышлары, республикада гамәлдә булган төрле проектларга багышлана. Аерым алганда, проект кысасында Россия Президенты гамәлгә куйган илкүләм проектларга багышланган фикер алышулар узачак. Чаралар концерт белән тәмамланачак. Марафонның беренче чарасы Лаешта узды. Аның максат-бурычлары турында Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов сөйләде.

– 2024 елда барлык илкүләм проектларның да вакыты чыга. Бүген безнең бурыч – алар ярдәмендә ирешкән нәтиҗәләр турында сөйләү, киләчәккә планнар кору, киләсе еллардагы проектларның нинди булырга тиешлеген ачыклау. Бүген без шактый мәгълүмат тупладык. Лаеш халкы белән очрашуыбызга шатбыз. Бик тырыш, аягында нык басып тора торган кешеләр яши монда, – диде ул.

Аның сүзләреннән аңлашылганча, илкүләм проектларның барысы да өч төп юнәлеш буенча бурычларны үтәүгә юнәлдерелгән. Беренчедән, кеше «капиталы», ягъни белем бирү, сәламәтлек өлкәсе, социаль тармак. Икенчедән, сыйфатлы мохит, ягъни юллар, ишегаллары һәм, гомумән, җәмәгать урыннары. Өченчедән, икътисад.

Сан

Соңгы биш елда Татарстанда илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга **180,7** млрд сум акча тотылган. Шуның **130** млрд сумы – федераль бюджет акчасы.

Фикер алышуда «Кече һәм урта эшмәкәрлеккә һәм шәхси эшкуарлыкка ярдәм» илкүләм проекты да телгә алынды. Аның турында Татарстан Рәисе ярдәмчесе, республиканың эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле Фәрит Габделганиев сөйләде.

– Әлеге проект кысасында 2023 елда Татарстан эшмәкәрләре 15,9 млрд сум күләмендә финанс ярдәме алды. Гомумән алганда, Татарстанда кече һәм урта бизнеста эшләүчеләрнең саны – 850 меңнән, ә үзмәшгульләрнеке 300 меңнән артык. Бу – республика халкының яртысыннан артыгы дигән сүз. Илкүләм проектларның мөмкинлекләрен киңәйтү өчен, республика программалары да бар. Әйтик, Татарстан Рәисе йөкләмәсе буенча интернет-сәүдәне үстерү өчен төбәк программасы кабул ителде, – дип сөйләде ул.

Билгеле, кабул итүче якка да сүз бирелде. Лаеш районы башлыгы Илдус Зарипов шулай ук район казанышларына, ирешкән уңышларга тукталды.

– Районның потенциалы көчле. Бу җәһәттән аның Казанга якын булуы да йогынты ясый. Районда инфраструктура яхшы, аэропорт та бездә, махсус икътисадый зонабыз да бар. Нәкъ менә шундый шартлар эшкуарларны, икътисадый актив кешеләрне районга җәлеп итә. Без исә, үз чиратыбызда, андый актив кешеләргә игътибар күрсәтәбез. Гомумән, республикада бар нәрсә дә контрольдә. Татарстанда начар эшләргә ярамый! – диде Зарипов.

Шулай итеп, «Татарстан – казанышлар республикасы» автобус марафоны чираттагы районга кузгалды. 1 мартка кадәр махсус автобус республиканың 29 районын йөреп чыгарга тиеш. Бүген ул Арчага юл тотты.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

АЛМАН ИЛЕНДӘ – «ТАТАР ЯЗЫ»

Милләттәш

Германиянең Бургхаузен шәһәрчегендә «Татар язы»н оештыручы милләттәшебез Разиф Хафизов, Казанда яшәүче абыйсына кунакка кайткач, редакциягә килеп чыкты.

– Очраклы гына «Ватаным Татарстан» газетасы кулыма килеп керде дә шунда әллә нәрсә булды: йөрәгем кысылып куйды. Үзе «Ватан», үзе «Татарстан». Исеме шулкадәр дөрес сайланган дип исем китте. Адресын карадым да аякларым үзеннән-үзе сезнең якка атлады. Мин инде сезнең белән күрешмичә китә алмас идем, – дип аңлатты ул үзенең бу адымын.

Улымны ташлап китә алмадым...

– Мин Үзбәкстанда туып-үстем, – дип таныштырды ул үзе белән. – Әнием – Уфадан, әтием – Башкортстанның Туймазы районыннан. Мәктәпне тәмамлагач, үз көнемне үзем күрергә дип, Мәскәүгә чыгып киттем. Армиядә хезмәт итеп кайткач, Спорт һәм мәдәният академиясенә укырга кердем. Ул арада өйләнеп, гаиләдә корып җибәрдем. Тормыш үз җилкәмдә бит инде. Финанс ягын кайгыртып, йортлар төзелешендә эшли башладым. Төзүче һөнәренең бик кирәкле икәнлеген аңлау миндә икенче югары белем алу теләген уятты. Инде яшәрлек акча эшләү, карьера мәсьәләсе дә хәл ителгән кебек иде. 2007 елда хатыным Аннага Германиядән чакыру килеп төште. Ул – немец милләтеннән, үзе Россиядә туып-үскән. Тарихи ватанына бик кайтасы килеп яшәде. Үземне нинди авырлыклар көткәнен белсәм дә, укуымны калдырып, әшемне ташлап, гаиләмә ияреп китәргә мәҗбүр булдым. Баладан аерыла алмадым чөнки. Гаилә тормышы гына барып чыкмады. Аерылыштык. Инде бөтенләйгә кайтып китәргә дип билет та алган идем. Аэропортка барырга вакыт җиткәч, уйланып утырам шулай: бердәнбер баланы язмыш кочагына ташлап калдырасың инде, син нинди әти кеше, дигән уй йөрәкне телә. Түзә алмадым, калдым. Туган илгә илтергә тиешле билетымны стенага ябыштырып куйдым. Ул миңа хәзер дә, хәтерне яңартып, үземне аклап тору өчен кирәк. Балама булыша алдым, шөкер. Югары уку йортын тәмамлап, физиотерапевт булып эшли. Аралашып яшибез.

Татар булуым ярдәм итте

– Яшермим. Башта бик авыр булды. Әмма мин үз алдыма максат куйдым бит инде. Егет кешенең сүзе бер булырга тиеш. Ялгыз калу өстенә алман телен дә белмим бит әле. Аралаша да, эшкә дә керә алмыйм. Мондый авыр хәлдән чыгарга татар булуым ярдәм итте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шулай бервакыт очраклы гына пиццериядә эшләүче төрек егетләре белән танышып киттем. Мөселман да булгач, хәлемә кереп, үзләренә эшкә чакырдылар. «Мин немецча сөйләшә белмим бит», – дип каршы килеп маташтым әле. «Башта кухняда гына эшләрсең. Эшли-эшли тел өйрәнү курсларына йөрерсең», – диделәр. Шулай иттем дә. Ярты көн эшлим, ярты көн тел өйрәнәм. Аннан үзләшеп киттем инде. Һөнәрләремне дә алыштыра башладым. Кабат төзелеш эшенә тартылдым. Хәзер мин үз һөнәрем буенча эшлим: мебель фабрикасында кухнялар җитештерәм. Яшәгән шәһәребез бик матур, кешеләре дә әйбәт.

Татар язы

– Мин сезгә үзем турында түгел, Германиядә яшәүче татарлар турында сөйләргә килгән идем бит әле, – диде Разиф Фәнилович, тормышы турында бер сулыштан сөйләп ташлагач. – Нинди генә җирләргә килеп чыксаң да, үз милләттәшләреңне очрату, аларның хәерхаһлыгын тою – гаҗәеп хис икән ул. Башта мин Франкфурт шәһәрендәге татарлар диаспорасы белән аралашып киттем. Армиядә пешекче булып хезмәт итүем ярап куйды. Чаралар үткәргәндә татар ризыкларын әзерләргә чакырдылар. Аннан төрле шәһәрләрдәге Сабантуйларда катнаштым. Берлинда да булдым. Бавариядә «Татар җәе», «Татар көзе» дип аталган бәйрәмнәргә йөрдем. Җәен – Сабантуй, көз көне гадәттә спорт бәйрәме үткәрәләр. Бу очрашулар минем күңелгә бәлзәм кебек булды.

> Шунда башымда: «Әнишләп әле җәй дә, көз дә бар, ә яз юк. Гадәттә татар төп бәйрәмен – Сабантуйны язгы кыр эшләре тәмамлангач үткәрә бит», – дигән уй кымырдый башлады. Үзем яши торган шәһәрдә яз бәйрәме үткәрергә дигән карарга килдем, теләктәшләр дә таптым.

Менә инде бу бәйрәмне җиде тапкыр үткәрдек. Германиядә татар диаспоралары төрле шәһәрләрдә эшләп килә. Кайвакыт каршылыклы фикерләр дә ишетергә туры килә. Мәсәлән, безнең төркемгә төрле илләрдән төрле милләт кешеләре җыела. Ә чараларның нигезендә барыбер татар тормышы ята. Татар уеннары уйныйбыз, татар ризыклары ашыйбыз, татар иле турында сөйләшәбез. Өчпочмаклар пешерергә инде ничә ел рус хатын-кызы ярдәм итә. Шулай итеп, мин башка ил, милләт кешеләренә татарлар турында сөйләргә тырышам, гореф-гадәтләрне күрсәтәм. Әйтергә кирәк, безне монда, Россиядән килгәч, барыбызны да диярлек руслар дип кабул итәләр, шулай гадәткә кергән. Татар милләтен белүчеләр, чыннан да, бик сирәк. Ә кем икәнлегебезне күрсәтәсе, белгертәсе килә. Шуңа күрә төркемдә башка милләт кешеләренең булуы, рус телендә сөйләшүебез начар түгел дип әйтәсем килә. Дөрес, кайберәүләр татарлар гына җыелып, татарча гына сөйләшеп утыруны хуп күрә. Алар да дөрес уйлыйлар, әлбәттә. Фикерләр күп төрле. Иң мөһиме, безгә бердәмлекне югалтмаска кирәк.

Тарих эзләреннән

Разиф Фәнил улы читтә илдә яшәсә дә, туган җире өчен файдалы эшләр эшләүдән туктамый. Сугыш эзләрен барлавы да – шуның бер дәлиле. Башта ул бу шөгыльне әбисенең Берлинда үлеп калган туганы Шәехсалих Салихов турында мәгълүмат җыюдан башлый. Кызыл Хачка, Мюнхендагы Россия илчелегенә мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә Лебус шәһәрендәге туганнар каберлегендә абыйсының исемен мәңгеләштерүгә ирешә. Туктап калмый. Германиядәге архивлардан әтисенең туган җире Туймазы районыннан сугышка китеп, алман илендә башларын салган якташларын барлаган. Исемлек шактый саллы күренә. Димәк, күпме кешеләр бабаларының, әтиләренең, туганнарының каберләрен таба дигән сүз бит бу. Шундый матур уйлар белән милләттәшебез Туймазы якларына юл тотты. Уңышлар телик аңа.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Ватан хакына

ТУГАН ЯК ҖЫЛЫСЫ

Сүз дә, гамәл дә кадерле. Махсус хәрби операция зонасыннан вакытлыча туган якларына кайткан егетләр белән очрашу сәгатьләре бик чикле. Шулай да районнарда аларның һәм гаиләләренең хәлләрен белешергә дә, бәйрәмнәрдә күңелләрен күтәрергә дә өлгерәләр. Халык белән берлектә җыелган гуманитар ярдәм машиналары да җибәрелә тора.

Бер очрашу...

Әлки районы башлыгы Александр Никошин хәрбиләр белән чираттагы очрашуын 11 гыйнварда уздырды. Очрашуга килгән өч батыр – Илгизәр Катеев, Александр Фурасев һәм «Андрон» позывноелы егет хәрби хезмәтләре турында сөйләде. Һәрвакыттагыча, зарланмыйча, үзләреннән бигрәк гаиләләрен кайгыртып. Әйтик, «Андрон»ның гаиләсенең яшәү шартларын яхшыртырга кирәк. Район башлыгы исә хәрбиләрнең гаиләләренә тиешле ярдәм күрсәтүне мөһим бурычларының берсе булуын әйтте. Ә егетләрнең үзләренә грамоталар һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

Балык Бистәсе егетләренең район башлыгы Радик Исламов белән очрашулары да шундыйрак рухта узды.

– Сезнең хәрби хезмәтегез бәяләп бетергесез. Без исә якыннарыгыз юлыккан барлык проблемаларны хәл итүдә ярдәм күрсәтергә тиеш, – диде район башлыгы, бу җәһәттән башкарыласы эшләрне үз контролендә алуны вәгъдә итеп.

Хәрбиләр исә якташларына һәм бөтен Татарстан халкына рухи һәм гуманитар ярдәм өчен рәхмәт сүзләрен җиткерде.

Артыгы юк

Әйтик, Зәй районы һәм шәһәрендә хәзерге вакытта маскировка челтәрләре үрү өчен 11 мәйданчык оештырылган. Күптән түгел бу эшкә Урта Баграж авылы халкы да кушылган.

– Җирлегебездә яшәүче халык ничек тә булса махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итәргә тырыша. Күптән түгел авыл халкы, акча җыеп, егетләргә исемле посылкалар җибәрде. Һәркем булышлыгын төрле юллары белән эзли. Сарсаз-Баграж клубында госпитальләр өчен эчке киемнәр тегәләр. Маскировка челтәрләренең хәрби зонада иң мөһим әйберләрнең берсе булуын аңлап, Урта Багражда яшәүчеләр челтәр үрергә керештe, – ди Баграж җирлеге башлыгы Павел Минеев.

Егетләргә ярдәм итү эшенә олысы-кечесе бергә кушылган. Әйтик, маскировка челтәрләре үрергә йөрүчеләрнең иң өлкәне Федора Красновага – 75 яшь.

Бу көннәрдә Апастан да чираттагы ярдәм кузгалды. Махсус хәрби операциягә киткән егетләр, райондашларының ярдәм сорап, район башлыгы Айрат Җиһаншинга мөрәҗәгать иткән булган. Алар өчен тиз арада «Шевроле Нива» автомобиле әзерләнгән, ул машинага волонтерлар үргән маскировка челтәрләре, район халкы җыйган азак-төлек төягәннәр. Моннан тыш, районда яшәүче Руслан Ромачков егетләргә квадрокоптер тапшырган. Апаслылар җыйган акчага 4 рация сатып алынган. Район башлыгы Айрат Җиһаншин әйтмешли, берлектә – көч!

Чаллыда яшәүче эшмәкәр Фәрит Зарипов исә дүртенче мәртәбә махсус хәрби операциядәге егетләргә гуманитар ярдәм илтергә китте. Хәрбиләр белән даими рәвештә элемтәдә тора ул.



– Егетләргә салфеткалар, газ баллоннары, сок, шоколад, су, скотч, батарейкалар, эчке һәм җылы киемнәр, азык-төлек беркайчан да артык булмый. Туганнарым, игелекле кешеләр ярдәме белән хәрбиләр сораган кирәк-яракны җыйдым да тагын сәфәргә киттем. Егетләребезгә бергәләп ярдәм итсәк, җиңү тизрәк якынаер, – дигән ул «Шәһри Чаллы» журналистына.

Ул арада Түбән Камада хәрбиләргә ярдәм йөзеннән чираттагы хәйрия акциясе башланган. Шәһәр мэры Рамил Муллин тәкъдиме белән башланган акция кысасында Түбән Кама халкы белән берлектә якташлары өчен мең амуниция җыелмасы сатып алу планлаштырыла, анда иң кирәкле әйберләр булачак. Берсенең бәясе якынча 15 мең сум тора.

– Аларны хәрбиләр белән киңәшләшеп әзерлибез. Һәр комплектка сыйфатлы җылы киемнәр, тезлекләр, балаклава, аптечка, аккумулятор һәм башкалар керәчәк, – диде Түбән Кама мэры.

Акцияне Ватанны саклаучылар көненә багышлаганнар. Барлык кирәк-яракны 10 февральгә кадәр туплап бетерергә ниятлиләр. Сүз уңаеннан, акциягә балалар да кушыла ала. Алардан исә хатлар, открыткалар һәм рәсемнәр көтеп калалар.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

15 января 2024 г. № 34/241

г. Казань

Об определении на территории Республики Татарстан избирательных участков для проведения голосования избирателей, не имеющих регистрации по месту жительства в пределах Российской Федерации, на выборах Президента Российской Федерации

В целях обеспечения реализации активного избирательного права граждан, не имеющих регистрации по месту жительства в пределах Российской Федерации, руководствуясь пунктом 6 статьи 27 Федерального закона от 10 января 2003 года № 19-ФЗ «О выборах Президента Российской Федерации», Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Определить на территории Республики Татарстан избирательные участки для проведения голосования избирателей, не имеющих регистрации по месту жительства в пределах Российской Федерации, на выборах Президента Российской Федерации согласно приложению.
2. Направить настоящее постановление в территориальные избирательные комиссии Республики Татарстан.
3. Направить настоящее постановление для опубликования в газеты «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан» и разместить на сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».
4. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на секретаря Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан Борисову Н.П.

Председатель Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан А.С. Кондратьев

Исполняющий обязанности секретаря Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан Р.Р. Валиуллова

Приложение к постановлению Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан от 15 января 2024 г. № 34/241

Перечень избирательных участков на территории Республики Татарстан для проведения голосования избирателей, не имеющих регистрации по месту жительства в пределах Российской Федерации, на выборах Президента Российской Федерации

№ п/п	Наименование территориальной избирательной комиссии	Номер участковой избирательной комиссии	Адрес участковой избирательной комиссии, наименование учреждения, где расположена комиссия с указанием телефонов избирательной комиссии
1	2	3	4
1.	Территориальная избирательная комиссия Советского района города Казани	Участковая избирательная комиссия № 350	Республика Татарстан (Татарстан), город Казань, улица Николая Ершова, дом 55, здание – МБОУ «Гимназия № 126» Советского района города Казани, тел.: (843) 272-58-64, 272-71-59
2.	Территориальная избирательная комиссия Центрального района г. Набережные Челны	Участковая избирательная комиссия №2101	Республика Татарстан (Татарстан), город Набережные Челны, проспект Мира, дом 54, здание – МБОУ «Средняя общеобразовательная школа № 25» г. Набережные Челны, тел.: (8552) 38-18-98, 38-42-88
3.	Территориальная избирательная комиссия г.Альметьевска	Участковая избирательная комиссия № 797	Республика Татарстан (Татарстан), Альметьевский муниципальный район, город Альметьевск, улица Ленина, дом 37, здание –ГАУК РТ «Альметьевский татарский государственный драматический театр», тел.: (8553) 31-97-38
4.	Территориальная избирательная комиссия г.Чистополя	Участковая избирательная комиссия № 2733	Республика Татарстан (Татарстан), Чистопольский муниципальный район, город Чистополь, улица Льва Толстого, дом 144, здание – МБОУ «Лицей № 1» Чистопольского муниципального района Республики Татарстан, тел.: (843) 425-24-44

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераннары: **Гарифуллина** Мәхәббәт Шәриф кызы, **Комиссарова** Людмила Викторовна, **Кочкин** Петр Дмитриевич, **Мөхәммәтгалиев** Габделбәр Габделгани улы, **Фатхуллов** Рәшит Насыйбулла улы, **Хантимеров** Миңнеилдархан Хантимер улы; Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш кертүләре өчен Бөек Ватан сугышы ветераннары: **Маркина** Валентина Гавриловна, **Турентинова** Эльвира Владимировна, **Фәттахова** Гадилә Гыйлаҗ кызы; җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераннары: **Камалиев** Әдип Сәгъди улы, **Субботина** Светлана Борисовна, **Фәрдиев** Илшат Атлас улы; җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Баһавиев** Айдар Рашат улы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе криминалистика бүлеге өлкән тикшерүчесе-криминалисты, юстиция полковнигы **Мещанов** Александр Михайлович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлекләре һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүләре өчен «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе – Казан биохимия һәм биофизика институты үсемлекләр физиологиясе һәм күзәнәк биологиясе бүлеге мөдире, баш фәнни хезмәткәре **Горшкова** Татьяна Анатольевна, «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе – Механика һәм машина төзелеше институты баш фәнни хезмәткәре **Федяев** Владимир Леонидович, җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен М. Вахитов исемендәге Казан химия комбинаты (Крестовниковларның элеккеге 1 номерлы сабын һәм шәм заводы) – «Нәфис Косметикс» акционер җәмгыятенең ремонтлау-төзелеш идарәсе 18 номерлы цехының монтажда такелажчысы **Гусев** Виктор Петрович, мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең филиаллар белән эшләү бүлеге башлыгы **Кадыйрова** Хәния Расыйх кызы, республиканың халыкара һәм тышкы икътисадый хезмәттәшлеген үстерүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасының Финляндия Республикасындагы сәүдә-икътисадый вәкиле **Рәхимуллина** Альбина Райнур кызы, финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Төбәк автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә системасы дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенең техник-икътисадый эшчәнлек һәм дәүләт сатып алуларын тәэмин итү бүлеге башлыгы **Ярочкина** Надежда Николаевна Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Мариинский дәүләт академия театры» федераль дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең балет артисты (Санкт-Петербург шәһәре) **Баһаутдинова** Ильмира Равил кызына, вокалчы артист (солист) **Макарова** Анастасия Сергеевнага, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы Халык уен кораллары дәүләт оркестры артисты **Маслакова** Марина Анатольевнага, «Салават» яшьләр үзәге дәүләт бюджет учреждениесе вокалчы артисты (солисты) **Харисова** Энҗе Газинур кызына, Казан шәһәре Идел буе районының «22 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең баянчы-артисты, концертмейстеры **Шәрипов** Булат Илшат улына, Туймазы татар дәүләт драма театры Башкортостан Республикасы дәүләт автоном мәдәният һәм сәнгать учреждениесе драма артисты **Нуриханов** Данил Мөкыйм улына, «Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Хисмәтуллин** Риваль Ринат улына, «Әкият» татар дәүләт курчак театры дәүләт бюджет учреждениесенең курчак уйнатучы артисты **Шаһгалиева** Альбина Рәзиф кызына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты» д**игән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының «Арча урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе урманчысы **Әкбәров** Фәргать Вәли улына, Татарстан Республикасының «Кама урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе-урманчысы **Шамилов** Альберт Фәрхетдин улына, «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең таксация һәм урман хуҗалыгы тармагы икътисады кафедрасы доценты **Хәкимова** Зөлфия Газҗан кызына **«Татарстан Республикасының атказанган урманчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш суд приставы **Закиров** Әнвәр Фәрит улына, Татарстан Республикасы прокуратурасының прокурорларның гражданлык һәм арбитраж процессларында катнашуларын тәэмин итү бүлеге өлкән прокуроры **Кириллов** Эдуард Викторовичка, Татарстан Республикасы прокурорының халыкара-хокукый хезмәттәшлек буенча өлкән ярдәмчесе **Чалмаев** Сергей Юрьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, әнисе

ПРИВАЛОВА Валентина Тимофеевна

вафат булу сәбәпле, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Привалов Игорь Анатольевичның авыр кайгысын уртаклаша.

Авыл фәлсәфәсе

«Этләрдә дә кеше язмышлары»

Салкын көннәрнең берсендә авыл кибетенә барсам, элекке укытучым, авылыбызның бик тә хөрмәтле кешесе Рауза апа Зиннәтуллина кибеттән чыгып килә. Исәнләшеп, хәл белешеп өлгермәдек, шул тирәдә тыныч кына утырып торучы аксыл саргылт төстәге эт, койрык болгап, Рауза апа янына килеп тә җитте.

– Сезнең этме? – дим. – Сакчы белән йөрисез икән…

– Безнең эт түгел ул. Түбәноч эте. Урамныкы. Берничә ел элек балаларга ияреп кайткан иде, шунда яшәп калды. Ничәнче кышын чыга инде… Балалар аңа исем дә кушты, өйләреннән ризык алып чыгып та ашаталар. Мин дә капка төбенә савыт чыгарып куйдым, көнгә берничә тапкыр җылы сөт, кайнар аш салам, килеп, ашап китә. Әле аннан калганы белән иясез мәчеләр сыйлана… Шулкадәр тыныч, шулкадәр акыллы эт инде менә. Җәй буе тавыклар, бибиләр урамда йөри, ник бер кош-кортны куркытып, тиеп карасын… Бәхетсез җан әмма… Ферма якында гына бит, аның ишегалдында өйгән рулонлы саламнар күп, шунда йоклый, диләр. Балалар бик ярата үзен. Әмма кеше саен, хуҗалык саен диярлек эт шул, бер кешегә дә сыймый. Ач түгел, шунысына сөенә торган.

– Уйлана торгач, этләрдә дә кеше язмышлары икән дим, – дип дәвам итә бераздан укытучым. – Менә бу этнең язмышы бер төрле. Икенчесе – бүген СВОда булган Рәниснең эте… Ул да ярымҗимерекояда калды… Ярый әле, Линузасы кайтты, ул югында аңа да ашарга салгалый идек…

Кайчандыр гөрләп торган бу нигез бүген бушап калды шул, кызганычка. Әниләре Раушания апа, игезәк улларын армиягә озаткач, алар өчен борчылып, сәламәтлеген югалтты. Алар кайтканда инде, авыруы көчәеп, 45 яшендә вафат та булды. Үткән ел этиләре Фарух абый да үлеп китте. Игезәкләрнең берсе – Фәнис гаиләсе белән Казанда яши иде, мобилизациянең беренче көннәреннән үк хәрби зонага җибәрделәр. Фәнискә повестка килгәнен белгәч, Рәнис тә хәрби комиссариатка барган булган, тик шул чакта этиләре авырып, урынга калды да, аны җибәрмәделәр. Әтиләре вафат булып, бераз вакыт үтүгә, контракт төзеп, ул да шунда китте. Тормыш иптәше Линуза белән аралары бозылып алган иде, шөкер, «кайнар нокта»га китәсен белгәч, килешкәннәр булып чыкты. Эте дә язмышы белән килешкән, ахры, сабыр гына хуҗасын көтә икән. Рәнискә (андагы барлык ир-егетләргә) тиз көннәрдә исән-сау әйләнеп кайтырга, көтүче якыннарына һәм җан ияләренә дә сөенеп каршы алырга язсын. – Болары Рауза апа белән сөйләшкәнне соңыннан күңел аша үткәрүләрдән.

– Өченче язмыш безнең Фәнисләрнең эте (Фәнис – Рауза апаның бертуган сеңлесе, шулай ук гомер буе башлангыч сыйныфларга белем биреп, ялга чыккан хөрмәтле кешеләрнең берсе – Гөлзада апаның улы), – дип дәвам итә уйлануларын Рауза апа. – Гөлзадаларга барган саен шаккатып кайтам: этләре ялт иткән, җылы ояда, кадердә яши. Буранлы, салкын көннәрдә алдын каплап та куялар. Менә монысы бәхетле язмышлы эт инде…

– Әле уйлап карасаң, авыл буенча гына да әллә нинди язмышлы этләр бардыр… – диештек.

…Рауза апа белән сөйләшкәннәр турында уйланып кайткан җирдән сискәнеп куйдым: зират яныннан каршыма бозау кадәр эт чыгып килә иде. Хуҗасы да күренми. Урамда кеше дә юк. Нишләргә белми туктап калдым. Шунда зират почмагыннан хуҗасы Илфат күренде. «Курыкмагыз, тими ул, тими», – дип кычкыра-кычкыра, адымын кызулатты. «Курыкмассың, – мин әйтәм. – Үзе зур, кыяфәте бигрәк куркыныч». «Алабайлар (өстәп, ниндидер сүз әйтте, этләр токымын белмим, өстәвенә, кызуланып килеп, сулышы капкан иде, шуңа аңламадым) бик тыныч, акыллы этләр, кешегә тимиләр. Үзегез эттән курыкканга гына шулай куркыныч кебек тоела алар», – ди Илфат. Дөрестер, этенең миндә гаме дә булмады, ничек килде, шулай үтеп тә китте.

Илфатлар безнең авылга күптән түгел күченеп кайтты. Шәһәр егете. Татарча аңлый, русча сөйләшә. Сүз уңаеннан, бик аралашучан, кулыннан эш килә торган егет. Бөтен өмәләрдә катнаша, инде үз кешегә әйләнде. Этләрен ел әйләнәсе прогулкага, авылдан читкә – басу-кырларга йөрткәннәрен күреп торсам да (гадәттә тау өстеннән, бауга бәйләп, җитәкләп алып баралар иде), бергә-бер очрашкан юк иде. Кыш көне тау өстеннән юл юк, шуңа күрә зират янына йөрергә алып чыккандыр инде. Аларның эте, авыл этләре кебек, гел бәйдә – сакта гына тормый. Биек итеп коймалап алган зур бакчаларында күп вакыт иркендә йөри. Аның язмышы да башка…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Премьера

Бар мөлкәтен тараткан Әстерхан ханының бай Казан тәхетенә дәгъва кылуында соңгы өмете булып ике тинтәк сугышчысы гына кала… Юк, тарих битләрен актарырга җыенмыйбыз. Тиздән дөнья күрәчәк «Яу» тарихи комедиясенең кыскача эчтәлеге шулай башлана. Тарих комедия була аламы ул, дисезме? Фильмның нәрсә турында булуын, анда кемнәр катнашуын да беләсегез киләдер?



СОҢГЫ ЯУ,

ЯКИ ТАТАР КИНОСЫНА ӘЛЕ НИЛӘР КҮРӘСЕ?

film24.pro

Беренче тапкыр

Аны төшерү тарихыннан башлыйк. 2016 ел. Фильмның продюсеры һәм аны башлап җибәрүче Рәис Шәйхетдинов тарихи декорацияләрдә татарча фильм төшерергә тәкъдим итә.

– Татар киносы тарихында бердәнбер очрактыр бу: «Миндә идея бар, безгә ярдәм кирәк», – дип кеше эзләп йөрү түгел, ә «Сез эшли аласыз бит, әйдә шундый бер фильм эшләп карыйк әле», – дип ярдәм тәкъдим итү, – ди фильмның сценарие авторы Альберт Шакиров. – Фильмны «Мунча ташы» эстрада театры артистлары белән бергә эшләүне дә ул тәкъдим итте. Аларның тулы сатирик коллектив булуы, тамашачының аларны якын итүе беренче планга чыкты.

Иҗат төркеменә килгәндә, режиссер – Айдар Габдрахманов, ә төп рольләрдә – Гамил Әсхәдулла, Искәндәр Мотыйгулла, Рөстәм Рахманкул, Рөстәм Хәсәнов, Әнфис Кәлимуллин.

Тарих һәм абсурд

Фильмның сюжеты – тулысы белән уйдырма. Аның максаты да – тарихка яңача караш ташлау түгел.

– Тарихи декорацияләр, борынгы заманнарга күз салу – бертөрле тарихи фон гына. Үзәктә Казан ханлыгы һәм Әстерхан ханлыгы булу кайчандыр нәкъ менә шундый вакыйгалар булган дигән сүз түгел. Мин шәхсән – тарихка бик сак һәм җаваплы карый торган кеше. Бу – һәрбер чор өчен универсаль булган фикерләрне, фәлсәфәне җиткерү, фильмның мәгънәсен шул антуражга «төреп» бирү өчен эшләнгән әйбер генә, – ди сценарист.

Фильмны карап, тарихи яктан хаталар эзләп интекмәскә кирәк ягъни. Бу очракта тарихи фон, чор үзгәрә, вакыт бара, ә кеше үзгәрми, дип әйтер өчен файдаланылган.

– Без XXI гасыр күзлегеннән карыйбыз: киемнәре дә элеккеге шикелле, элеккеге хәлләр турында да сөйләшәләр, ләкин ни өчендер безнең заман турында сөйләгән шикелле бит. Менә шул эффектны тудырырга кирәк иде безгә, – дип аңлатты Альберт Шакиров.

Гел сәхнәдә чыгыш ясаган эстрада театрын кинога төшерү авыр булдымы икән? Моны да Альберт Шакировтан сорадык.

– Фильмның форматы, андагы юмористик сәхнәләр «Мунча ташы»ның конкрет образларын исәпкә алып эшләнде. Сүзләр, текстлар, кадрдагы «кыланмыш»лар да аларга яраклаштырылган иде. Шуңа да, юк, авыр булмады, – диде ул.

Фильмда без ияләшкән сатирадан тыш абсурд юмор да булачак. Бу җәһәттән төшерү командасы узган гасырның 60–70 нче елларында Бөекбритания, ә соңыннан бөтен дөньяда танылу алган «Монти Пайтон» юмор төркеменә күз салган. Татар киносы өчен үзенә күрә яңалык дип кабул итик.

Ә фильмның шулай озак төшерелеп җитештерелүе менә нәрсәгә бәйле булган:

– Төшерү процессы да, җитештерү процессы да параллель рәвештә барды. Шактый күләмле хезмәт. Беренчедән, 40–50ләп кешене җыйган сәхнәләр дә, аның кадәр кеше генә аз тоелган чаклар да булды. Икенчедән, кием-декорацияләр. Тарихи фон булгач, аңлашыла инде: аларны эшләп өлгертү җиңелләрдән булмады. Аннан соң, эшкә алынганда тәҗрибә булмау, мондый тулы метражлы фильмга беренче мәртәбә алыну да бераз кыенлыклар тудырды, – диде Альберт Шакиров.

Киноны концерт

Үзенчәлекләр моның белән генә бетми. Ялгышмасак, татар киносын концерт рәвешендә тәкъдим иткәннәре юк иде әле. Дөрестән дә шулай булса, тәүге киноконцерт 18 гыйнварда «УНИКС» концертлар залында узачак. Шулай итеп, «Яу»ны «Татар киносы ниләр күрми…» концертында тәкъдим итәчәкләр.

– Фильмны төрле эстрада артистларын чакырып тәкъдим итү – безнең өчен яңалык, – ди киноконцертның режиссеры Марсель Мәхмүтов. – Концертның сюжеты буенча продюсер белән режиссер арасында бәхәс бара: ни өчен татар халкы киноларга йөрми, ни өчен карамый, ни өчен эстрадага мөкиббән халык?

Киноконцертта фильмда катнашкан һәм катнашмаган Салават Фәтхетдинов, Иркә, Гөлназ һәм Илсур Шәрипҗановлар, Илнат Фәрхуллин һәм башка җырчыларның булуы көтелә.

Фильмны да 18 гыйнвардан тарата башларга ниятлиләр. Аны кинотеатрларда түгел, түләүле сылтама аша карап булачак. Кайдан һәм ничек икәнен бераз соңрак игълан итәргә вәгъдә бирделәр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

12+

Соклану

ИСКЕГӘ ҖАН ӨРҮЧЕ

Саба районының Олы Кибәче бакчасы тәрбиячесе Диләрә Мөхәммәтшина иске-москы әйберләрнең берсен дә әрәм итми. Табылдык чемодан белән республика бәйгесендә катнашып, беренче урынны алган ул. Чын мәгънәсендә, уйлап табучы, дисәң дә була аны.

Тумышы белән Килдебәк авылы кызы ул. Кияүгә чыкканына – 18 ел. Ире Зөлфәт белән ике ул тәрбияли. Моңа кадәр татар теле һәм әдәбияты укытса, хәзер тәрбияче булып эшли. Чигәргә, кул эшләренә, тортлар пешерергә дә оста. Ризыкларын сораучылар аз түгел.

Бакчага 33 бала йөри. Алар өчен дә нинди генә уеннар уйлап тапмый да ниләр генә ясамый тәрбияче. Һәрбер хезмәтендә миллилекне чагылдырырга тырыша. Диләрә әйтүенчә, максаты – шаккатыру түгел, борынгы җиһаз, йола, гореф-гадәтләрне югалтмыйча балаларга җиткерү.

– Капрон колготкиның да кирәге чыкты. Аннан физкультура дәресендә күнегү ясау өчен җайланма ясадык. Ул әйбәт сузыла һәм йомшак. Сыек май шешәсе бөкеләрен дә ташламыйм. Аны 3–4 ел буе җыйдым. Эчендәге бөҗраларыннан чылбыр үрәбез. Кемнеке озынрак дип ярышабыз да әле. Йомырка савытларын төрле төсләргә буяп, пазллар эшләдек. Карап торышка бик җиңел кебек. Әмма дөрес итеп туры китермәсәң, җыеп булмый, – ди Диләрә Мөхәммәтшина. – Тәрбиячегә бер әйбер дә артык түгел. Бәйгеләрдә катнашканда барысы да эшкә ярый. Бакчадагы складны җыештырырга мине алып баралар, чөнки бер нәрсәне дә ташламыйм. Кул эшләребез бик күп. Бакчабыз кечкенә булгач, барысын да сыйдырып булмый шул. Шуңа күрә сандыкта да сакларга туры килә.

Яңа бәйгеләр игълан иткәнне көтеп кенә тора тәрбияче. Көн-төн буе уйлап йөри дә ниятен тормышка ашырырга керешә. Курчаклар ясап, аларга күлмәкләр тегә, толымнар үрә, муенса, алкалар киертә. Чигүгә дә оста әле ул. 42 яшьлек Диләрә үзе дә сизмәстән сабый балага әйләнә дә куя. Районда оештырылган «курчак театры» бәйгесендә беренче урын алган. Балаларга юл кагыйдәләрен өйрәтү өчен лэпбук ясаган. «Милли келәм» дигән уен да – аның хезмәте. Киезләрен табарга җиһаз кибетендә эшләүче сеңлесе булышкан. Калдык-постык тукыма келәмгә яраган. Шунда төрле бизәкләр һәм биремнәр ябыштырган. Бәйрәмнәргә дә үз өлешен кертә. Хезмәттәше Ләйлә Гайфуллина белән исә «Каз өмәсе» өчен кирәкле бар нәрсәне үзләре ясаган. Шул рәвешле, балаларга, әти-әниләргә борынгы йоланы, миллилекне күрсәткәннәр.

Чемодан – үзе тарих. Аны ире очраклы гына шәһәрдәге чүплектән табып алып кайткан. Өр-яңа, хәтта бәясе дә алынмаган. Эш коралларын салып йөртергә менә дигән. Тик Диләрә кулына эләксәме? «Тылсымлы чемодан» бәйгесендә катнашыр өчен менә дигән табылдык булган. Ул аны әнә ничек затлы иткән бит!

– Каенатам Наил – балта остасы. Бар нәрсәне төптән уйлап эшли. Көрәк сабыннан өйнең эчен тышлады. Идән җәйдек, тәрәзә ясадык. Улларым Сәйдәш белән Сәид тә булышты. Биш көн вакыты китте моңа. Өй эчен матур итеп киендердем, шәмаилләр элдем. Өч кызны урнаштырдым. Курчакларны ике атна буе тектем. Үзебезчә бик тырыштык инде. Узган ел ахырында «Чемоданда әкият» номинациясендә җиңүебезне хәбәр иттеләр. Гаиләбезнең көче керде бит. Барыбыз да сөендек инде, – ди Диләрә Мөхәммәтшина.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 4668 данә
Гомуми тираж – 13856 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 205

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+